КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1197

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2026 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2026 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 12 июль, 567 нче; 2019 ел, 8 ноябрь, 1023 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1279 нчы; 2020 ел, 12 июнь, 483 нче; 2020 ел, 11 декабрь, 1117 нче; 2021 ел, 9 август, 693 нче; 2022 ел, 12 май, 434 нче; 2022 ел, 20 октябрь, 1115 нче; 2023 ел, 5 июнь, 690 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгын дәүләт программасының җаваплы башкаручысы итеп билгеләргә.»;

3 пунктта:

«чираттагы финанс елына» сүзләреннән соң «һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

«Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2019 – 2026 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарга теркәлгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин